ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2023 г. Казань № 836-65/т-2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.06.2023 №70-1/т-2023 карары белән расланган Татарстан Республикасында сәнәгать тимер юл транспорты оешмалары һәм башка хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан керү тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә тарифлар билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 27.12.2023 №65-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.06.2023 №70-1/т-2023 карары белән расланган Татарстан Республикасында сәнәгать тимер юл транспорты оешмалары һәм башка хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан керү тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә тарифлар билгеләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

V бүлекнең 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Тарифларны исәпләү өчен, оешма тарафыннан һәр заказчы өчен йөк әйләнеше (вагон әйләнеше) башка оешманың тоташу станциясенең күргәзмә юллары күчешеннән яки оешма станциясеннән йөкләү (бушату) фронтына кадәр, шул исәптән оешманың үз күләмен, әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта буенча мең тоннада исәпкә алып, ташыла торган йөк күләме буенча мәгълүмат бирелә.

Ташыла торган йөкләрнең бәясе, бөтен санга тигез булмаган арага, билгеләнгән тарифка пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Ташу ераклыгы километрларда өтердән соң өченче билгегә кадәр төгәллек белән билгеләнә.

Ташыла торган һәм җыештырыла торган вагоннарда, контейнерларда ташыла торган йөкнең авырлыгын (массасын) исәпкә алу күп әйләнешле транспорт савытының авырлыгын (контейнер, универсаль һәм махсуслаштырылган контейнер, типоразмерны, махсус алынмый торган җиһазларны (ложементлар, метизлар һ.б.) исәпкә алып башкарыла.»;

VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VIII. Тарифны исәпләү

Тарифлар һәр аерым бүлекчә буенча үлчәү берәмлеге (тонна) өчен саннар белән исәпләнә һәм билгеләнә (бу Тәртипкә 4 нче, 5 нче кушымта буенча).

1 тонна йөк ташуның һәр километры өчен тариф түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Тп = (З + П) / Qгр,$$

биредә:

З – вагоннарны тапшыру-җыештыру чыгымнары, станцияләр кисемендә һәм гомумән оешма буенча, мең сум;

П – станцияләр кисемендә һәм гомумән оешма буенча табыш, мең сум;

Qгр – барлык кулланучылар буенча, шул исәптән үзенеке буенча, станцияләр кисемендә һәм гомумән оешма буенча йөкләр ташу күләме (тонналарда).

Җиңел йөкләр өчен расланган тарифка карата 3,2 коэффициенты кулланыла.

Җиңел йөкләрне ташу вакытында оешмага әлеге Тәртипнең 4.1 пунктына ярашлы рәвештә керемнәрне һәм чыгымнарны аерым исәпкә алырга кирәк.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина